РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

Исполнительный комитет
Чубар-Абдулловского
сельского поселения
Азнакаевского
муниципального района

ул. Советская, д.81, с.Чубар-Абдуллово, 423323
Тел. (8-292)38-7-30, 38-7-37

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Азнакай муниципаль районы
Чубар-Абдул авыл жирлеге
башкарма комитеты

Совет урамы, 81, Чубар-Абдул авылы, 423323
Тел. (8-292) 38-7-30, 38-7-37

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ                                                                                    КАРАР
«08» декабрь 2017 ел.                                                                              № 21

**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Чубар-Абдул авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә урыннар бирү тәртибе турында**

"Россия Федерациясенең аерым закон актларына гавами чаралар турындагы законнарны камилләштерү өлешендә үзгәрешләр кертү турында" 2017 елның 7 июнендәге 107-ФЗ номерлы, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында"2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законнар,Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Чубар-Абдул авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә,карар бирәм:

1. Раслау:

-Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Чубар-Абдул авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә депутатларның сайлаучылар белән очрашуларын уздыру өчен махсус бирелгән урыннар исемлеге (1 нче кушымта);

-Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Чубар-Абдул авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә депутатларның сайлаучылар белән очрашуларын уздыру өчен биналар исемлеге(2 нче кушымта);

-Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Чубар-Абдул авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә депутатларның сайлаучылар белән очрашуларын уздыру өчен урыннар бирү тәртибе (3 нче кушымта).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Башлык                                                                Фәтхетдинов Н.А.